«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 7 нче гомуми урта белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе

# Апаста туган якны өйрәнү

(Музейлар - хәтер почмагы)


Укытучы : Хәмидова З.З

Башкарды: 8нче сыйныф укучысы Нуруллина Лилия


2020 ел

Эчтәлек

1. Кереш
2. Музейның эшчәнлек тарихы.
3. Даими эшләүче экспозицияләре.
4. Музей тупламасындагы уникал экспонатлар.
5. Соңгы елларда музей эшчәнлеге.
6. Кулланган әдәбият.

## Кереш

Апас ягы – матур, гүзәл як. Ул безнең генә түгел, борынгы болгар бабаларыбызның да торган җире, гомер бишеге. Алар күп гасырлар элек биредә, бу территориядә яшәгәннәр, иген иккәннәр, ауга йөргәннәр, үзләреннән соң матур йола-гореф-гадәтләр, яңа буыннар калдырып киткәннәр. Бу тарих бик зур һәм ул Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына барып тоташа. Фактларга килсәк, “Татарстан тарихы” китабында хәзерге Апас районы җирләрендә кешеләрнең 12-14 мең еллар элек үк утрак тормышка җайлашулары, ягъни төпләнүләре турында мәгълүмат бар. Бүгенге көндә район танымаслык булып үзгәрде. Искитмәле матурлык, хозурлык хөкем сөрә Апаста! Апас районы музейларга да бик бай. Минем эшем шушы Апас районының Туган якны өйрәнү музее турында. Әлеге төбәк турында күбрәк белергә теләсәң, әлбәттә, ул музейларда булырга кирәк.Ә инде музейның җитәкчесе Рәмис Госман улы Ногманов кебек бик тә ачык, киң күңелле искиткеч зыялы, кызыклы шәхес булса, биредә күпме вакыт йөрүеңне дә онытасың, чөнки тарих белән очрашканда вакыт төшенчәсе икенче планга күчә. Рәмис абый музей белән таныштырды. Мин зур кызыксыну белән барлык экспонатларны карап чыктым. Һәр бүлектәге стендлар, стенага ясалган рәсемнәр эчтәлеге һәм матурлыгы белән үзенә җәлеп итте. Күргәзмәләрдәге әби-бабалардан буыннан-буынга күчеп килгән әйберләрнең кадерләп саклануы, туган төбәккә һәм аның халкына тагын да зур хөрмәт күренә. Күптөрле һәм эчтәлекле экспозицияләр төбәкнең үткәнен өйрәнергә; халкыбызның гореф -гадәтләренә, матур традицияләренә

ихтирам тәрбияләүдә, тарихның төрле чорларында  Апас төбәге үсешенә зур хезмәт куйган шәхесләр, Бөек Ватан сугышы каһарманнары, оешмалар турында күбрәк белергә ярдәм итәләр, дип уйлыйм.

## Музейның тарихы

Музейның рәсми тарихы 1991 елның 14 октябреннән башлана. Беренче көннәрендә мәктәпнең бер бүлмәсендә урнаша, соңрак мәдәният йортының икенче катына күчерелә. Музей фондлары район территоиясендә уздырылган экспедицияләр вакытында укучылар тарафыннан табылган әйберләр белән тулыланып тора. 2005 елда музей заманча бизәлгән, иркен, зур бүлмәле,

500м кв. м. мәйданлы махсус бинага күчә. Музей ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, РФ атказанган укытучысы, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү һәм иҗади эшләр конкурсында җиңүче, 16 музыкаль инструментта уйный белүче бик хөрмәтле   Рәмис Госман улы Ногманов җитәкчелеге астында эшли башлый. Музейның коллекциясе 15 000 саклану берәмлеге исәпләнә, аларның тарихы, килеп чыгышы турында белешмәләр бирелгән. Апас туган якны өйрәнү музееның өч структур бүлекчә (өч филиалы)бар:

Тутай авылында — Сара Садыйкова, Шәмбалыкчыда — Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева, Бакырчыда — Шәүкәт Галиев музее.

Бөтен район халкы, укучылар ярдәме белән археология залларында тарихи кыйммәткә ия 15 меңгә якын (14 914) экспонат саклана, шуның 9 100 үзәк музейда. Монда нәрсә генә юк!  Музейны тулыландыру максатыннан аерым кешеләрдән, шәхси коллекционерлардан тарихи әйберләр, истәлекле язмалар җыйганнар.

### Даими эшләүче экспозицияләре

Музейда 7 төрле юнәлештә даими эшләүче экспозиция залы бар:

- Археология һәм табигать залы;
- Революциягә кадәр чор;
- Татар авылы этнографиясе һәм йорт җиһазлары;
- 1917-1940 еллар, НЭП, коллективизация һәм репрессия чоры;

- Бөек Ватан сугышы 1941-1945 еллар;
- Районның танылган кешеләре;
- Типография һәм районның бүгенгесе.
- Мәсәлән, Зөя буендагы Кабыккупер авылы янында археологлар төрле ау һәм балык тоту кораллары табалар. Сөяктән ясалган ыргаклы сөңгеләр, эләктергечләр һәм очлыклары шулай ук Зөягә орынып ук утырган Дәвеш авылы янындагы торфлыкта яшәгән борынгы кешеләр торагында да табыла.

Һәр зал экспозициясендә дә бай материаллар тупланган. Аларның иң зурысы «Данлыклы якташларыбыз» һәм «Археология һәм табигать» залы. Бары тик Апас туган як музеенда гына булган уникаль экспонатлар аеруча игътибарга лаеклы.

**Музей тупланмасындагы уникаль экспонатлар:**

- 1,5 млн. ел элек бу төбәктә яшәгән, хайваннар калдыгы (мамонт бәрмә-тешләре һәм балтыр сөякләре, йонлач мөгезборынның баш сөяге, бизон һ. б.)

-Аммонит (киселгән) – 65 млн. яшь тирәсендәге моллюск

- Дирхәмнәр – XIII гасырга караган Алтын Урда акчасы

- XIII-XIV гасыр ризык пешерә торган казан

- С. Садыкованың калфагы (татарларның милли баш киеме)**,**уен кораллы

- Садри Җәләлнең оныгы бүләк иткән, моннан ике-өч гасыр элек эшләгән, “Зингер” машинасы, шкаф

-1904 елгы америка фисгармониясе(уен коралы)

- Сугыш кырларындагы эзләнүләрнең яңа табылдыклары (каска, крушка, дарулар һ. б.)

- Сугыш еллары журналлары

- Деушев борынгы шәһәр урынында табылган (тауның көнчыгыш ягында) VI – XIV гасырга караган бөти-амулет (бүре казык теше)

- Сугыш чоры трофейлары, фронт хатлары

- Алтын Урда чоры Әзгәри акчалары, 13-14 гасырга караган казан, савыт-сабалар, эш кораллары, этнографик, палентология табылдыклары.

Татар халкының күренекле шәхесләре белән бәйле экспонатларбар.Аларның килеп чыгышы, тарихы турында белешмәләр бирелгән Музей хезмәткәрләре

бертуктаусыз эзләнү эшләре алып баралар. Апас төбәге, Апас кешеләре белән бәйле булган күренекле шәхесләр турында да күп кенә кызыклы материллар белән дә музейда танышырга мөмкин. Мисал өчен:

**Гаяз Исхакыйның** бертуган сеңлесе Гайнелмәрзия кызлары белән сугыш чорында Апас якларында яшиләр. Кызлары Сөймбикә медицина хезмәткәре булып эшли. Музейга язган хатлары саклана. Икенче кызы Рауза Дәүләки МТСында агроном булып эшли. Апас зиратына күмелә.

**Габдулла Тукай** белән Апас районы Ябалак авылыннан Габдулла Харис 1911-13 елларда иҗадый элемтәдә булып яшәүләре тагын бер өстәүле мәгълүмат. Казанда мәдрәсәдә укыганда Габдулла Харис беренче шигырьләрен яза башлый. Габдулла Харис Габдулла Тукайның шәкерте була. Ул аның янына еш бара, язган шигырьләрен укый, күрсәтмәләр ала

**Муса Җәлил** Мәскәүдә “Эшче” газетасында эшләгән чорда, Апастан Мотыйк Гыйсмәтуллин һәм Миңневәли Миннегалиевлар шул редакңиядә типография хезмәткәрләре булып эшлиләр Кайчандыр аларда калган Җ,Ф хәрефләре дә саклана.

**Һади Такташ** та күпмедер Апас төбәге белән бәйле. Гөлчир Бикмурзина, Такташның беренче хатыны, -Апас кызы

**Абдулла Алиш** шигырьләрен алып кайтучы Газыйм Кадыйров Апас районы Кызыл Тау (Коллар) авылы каһарманы. Алиш белән әсирлектә бергә булып, (Седльце лагере, Польша) аның шигырьләрен ятлап, Татарстан Язучылар союзына тапшыруы мәгълүм

**Соңгы елларда музей эшчәнлеге**

2017 ел музей өчен бик уңышлы ел була. 152 кв. м. мәйданлы уникаль проект белән палеонтология экспозициясе өчен янкорма төзелә. Экспозициягә куелган гигант мамонт, пермь чорына караган сөйрәлүче җир-су хайваннары макетлары эшләнә. Мамонтның биеклеге 2, 85 метр, авырлыгы 10 тонналап, янында кечкенә мамонт та бар. Бу уникаль залда Ишәй авылыннан ерак түгел Үләмә елгасы тирәсендә табылган палеонтологик табылдыкларга нигезләнеп, бу якта яшәгән борынгы хайваннар (мамонт, бизон, мөгезборын

һәм сөйрәлүче җир-су хайваннары) дөньясы күрсәтеләчәк. Макетлар һәм экспонатар барлау эше дәвам итә. Төрле тәрбия чаралары, күргәзмәләр, традицион булмаган дәресләр үткәрү, район үзәгенең урам-скверында бюстлар, тарихи корылмалар белән тамашачыларны таныштыру ачык һавадагы музейны хәтерләтә. Экскурсияләр уздыру музей эшчәнлегенең бер тармагы булып тора.

Апас туган якны өйрәнү музее «Музей-күргәзмә эшчәнлеге» номинациясе буенча «Жили-были» «Яшәгән иде...» (*А. Пушкин һәм Г. Тукай әкиятләре буенча*) проекты белән катнашып, ТР югары бүләге – 400 мең сумлык Грантка лаек була. Проектны музей коллективы төзи. Балалар өчен үтә кызыклы экспозицяне төзү шул Грант акчасына дәвам итәчәк. Һәйкәл монументлардагы сугыш чоры тракторчы хатын-кызлар, атказанган исемен йөртүче,орденлы
районаашларның, Ленинордены кавалерларының, Социалистик Хезмәт Геройларының исемлеген, фотоларын барлау, районның һәм ТР беренче шәхесләре мәгълүматларын барлау музей хезмәткәрләренең зур хезмәт нәтиҗәсе дип әйтәсе килә. «Я - гражданин России» («Мин - Татарстан баласы») эше белән музей хезмәткәрләре мактаулы 3 урынны яулады, диплом белән бүләкләнде. Музейда тәрбия чаралары үткәрү өчен мөмкинлекләр бар. Шундыйларның берсе - 14 яше тулган яшүсмерләргә тантаналы төстә паспортлар тапшыру. Ул һәр айның соңгы пәнҗешәмбесендә төштән соң 14 сәгатьтә башкарыла. Анда культура хезмәткәрләре дә катнаша, иң мөһиме, район Советы, «Яшь гвардия» вәкилләре дә, ата-аналар да катнаша һәм дәрәҗәле үтә. Узган ел 500гә якын бала рәсми Россия документларын ала.

Музейда елына уртача 7-8 мең кеше була. Бигрәк тә балалар кызыксынып киләләр. Тиздән музей залларында диннәр дуслыгы, халыклар бердәмлегенә багышланган чираттагы зур чара үткәреләчәк. “Тагын бер башлангычыбыз белән уртаклашасым килә - Апас районы оешуга 90, ТАССР га 100, Бөек Җиңүнең 75 еллыгына апаслылар һәм музей тамашачылары арасында

“Нинди матур минем Апасым“ исемле фоторәсемнәр конкурсына старт бирелә. "Аларны безнең электрон адреска юлларга мөмкин" - ди Рәмис абый Ногманов. Музейда уздырылган һәр чара (экскурсия, дәрес, батырлык дәресләре, сугыш ветераннары белән уздырылган кичәләр) зур тәрбияви һәм танып-белү үзенчәлегенә ия.

Музейның һәр бүлеге һәм андагы һәр экспонат, экскурсоводларның мавыктыргыч сөйләме һәр кеше күңеленә үтеп кереп, тирән эз калдыра. Музей эшчәнлеге аша балалар күңелендә туган якты хисләр, һичшиксез, аларны чын патриотлар итә.

## Йомгаклау

Апас төбәгеннән күп кенә күренекле шәхесләр чыккан. Аларның күбесе башка җирләрдә эшләп дан казанганнар. Ә менә шуларны эзләп табып, туган яклары белән тоташтыру һәм алар белән элемтәдә тору Рәмис абый кебек фидакарьләрнең, музей эшчеләренең зур хемәте. Ни генә дисәң дә бит, музейлар бүгенгене, киләчәкне үткән белән тоташтыручы күпер кебек ул.
Бу эштә тарихны, үз төбәген яратмаган кешеләр эшли алмыйдыр ул, мөгаен.

Музее тик тормый, ул һаман саен үзенең байлыгы белән уртаклаша. Музей көннән-көн үсә, матурая, тарихи экспонатларга байый. Район халкы, укучылар бүген дә музейны истәлекле әйберләр белән тулыландырып торалар.
Шундый музей эше белән якыннан таныштырган Рәмис абыйга зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Эшләрендә зур уңышлар телим.

Әдәбият

1. Апас туган якны өйрәнү музее. Апас, 2012 ел.
2. Шәүкәт Галив музее. Апас, 2011 ел.
3. Музей директоры Рәмис Госман улы мәгълүматлары.
4. Үткәнне тәнкыйтьләмик, ә гыйбрәт алыйк. Татарстан яшьләре, 2017 нче ел, 12.10, 8нче бит.


АПАСТОВСКИЙ КРАЕВЕДЧЕСКИЙ
МУЗЕЙ





